ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

24.01.2020 ел Баулы шәһәре №11

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге 108 номерлы карары белән расланган (2019 елның 24 июлендәге 218 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге 108 номерлы карары белән расланган (2019 елның 24 июлендәге 218 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2нче "Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты" бүлегендә:

- 2.4. пунктта. "җиде эш көне" сүзләрен "биш эш кененә" алмаштырырга;

- 2.16 пункттагы икенче абзацта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә, объектны файдалануга тапшыруга рехсәт бирү турында гаризада күрсәтелгән очракта, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә.";

"административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең

читтә урнашкан эш урыннарында административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре":

- 3.5.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы 12 өлеше һәм 52 статьясы 3.3. өлешендә каралган очракларда капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү этапларына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында яисә рехсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Капиталь төзелеш объектын тезү, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рехсәт бирү турында гариза бирелсә, 2.5 пунктының 4, 5-11 пунктларында күрсәтелгән документлар капиталь тезелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең тиешле этабына кагылышлы өлешендә рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән очракта капиталь тезелеш объектын төзү, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризада капиталь төзелеш объектын тезү, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга элегрәк бирелгән рөхсәтләр (булганда) турында белешмәләр күрсәтелә.»;

3.7.1. пунктның җиденче абзацында «төзелешкә рехсәт бирү турында гариза алган көннән алып еч эш кененнән дә соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru.) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров